**ГЛАВА МАКАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**422602 Республика Татарстан**
**Лаишевский район с.Ташкирмень**
**ул.Мира д.40**
**тел: 8-(84378) -4-85-25**
**факс: 8-(84378) -4-85-25**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАКАРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
**422602 Татарстан Республикасы Лаеш районы Ташкирмән авылы**
**Тынычлык урамы,**
**40 нче йорт**
**тел: 8-(84378) -4-85-25**
**факс: 8-(84378) -4-85-25**

---

2024 елның 24 июне 3 номер

# КАРАР

**Җир кишәрлеген шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясына, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Макаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясына нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүне тәэмин итү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Макаровка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы,Лаеш муниципаль районы, Макаровка авылы, Совет урамы адресы буенча урнашкан 1185,96 кв. м. мәйданлы 16:24:120101:55 кадастр номерлы 13Г җир кишәрлеген«гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләре» ннән «бакчачылык алып бару»га шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Макаровка авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә 2024 елның 24 июлендә 16.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Ташкирмән авылы, Тынычлык урамы, 40 йорт адресы буенча Макаровка авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында ачык тыңлаулар уздырырга.
3. Ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне Татарстан Республикасы Лаеш районы, Ташкирмән авылы, Тынычлык урамы, 40 йорт адресы буенча 2024 елның 23 июленә кадәр язма рәвештә җибәрергә.
4. Әлеге карарны "Кама ягы"(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Макаровка авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга(халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге Советы рәисе вазыйфаларын башкаручы** **В.В.Кормачев**